| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮЛСУБИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЮЛСУБИНО АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.03.2020 № 7

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Юлсубино авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының 2004 елның 24 мартындагы “Җирле референдум турында” 23-ТРЗ номерлы Законы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Юлсубино авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, 2019 елның 30 октябрендә Юлсубино авылында узган гражданнар җыенында кабул ителгән 1,2 номерлы карарын, 2019 елның 31 октябрендә Ямаш авылында узган гражданнар җыенында кабул ителгән 1,2 номерлы карарын тормышка ашыру максатында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Юлсубино авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыюның кушымта итеп бирелә торган Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы,Юлсубино авылы Татарстан урамы, 56а йорт, Ямаш авылы, Х.Такташ урамы 3в йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге Башкарма комитетының баш бухгалтеры Назмие Фәнис Хәннан улына йөкләргә.

Балык Бистәсе муниципаль районы
Юлсубино авыл җирлеге
Башлыгы Х.Х.Гатиятов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Юлсубино авыл җирлеге
Башкарма комитетының 2020 елның
19 мартындагы дагы
7 номерлы карары
белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
“ Юлсубино авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә
гражданнарның үзара салым акчаларын җыю
Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “_Юлсубино авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Юлсубино авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан (белем алуның көндезге формасында укучы студентлардан гайре, аларның саны җирлектә яшәүчеләрнең гомуми санының 30 процентыннан артык була алмый) гражданнар җыенында катнашуларына һәм тавыш биргәндә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә2020 елның 31 мартына кадәр башкарыла.

3. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә бланкы (әлеге Тәртипкә кушымта) гражданнар игътибарына Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда игълан итү һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру (халыкка белдерү) ысулы белән, шулай ук кул куйдырып тапшыру юлы белән яисә почта аша юллап җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчасын күчерү реквизитлары, тулы яисә киметелгән күләмдә бер тапкыр түләнә торган түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

4. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “_Юлсубино авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең лицевой счетына керә.

5. Гражданнар тарафыннан түләүләр акча средстволарын физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган, почта переводларын (исәп-хисап оешмалары) гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар аша, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге Башкарма комитеты кассасы аркылы яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү

юлы белән башкарыла.

6. Түләү фактын раслаучы булып керем (приход) касса ордерының тамганамәсе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

7. Гражданнарның билгеләнгән срокта кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
“Юлсубино авыл ) җирлеге”
муниципаль берәмлеге территориясендә
гражданнарның үзара салым акчаларын
җыю Тәртибенә КУШЫМТА

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы “Юлсубино авыл җирлеге”
муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча
бер тапкыр түләнелә торган түләүне түләү турында
ХӘБӘРНАМӘ №_________

Түләүченең Ф.И.А.и.
______________________________________________________________________
Адрес: ___________________________________________________________
_______________________________________________________________нигезендә
Сезгә 2020 елның 31 мартына кадәр_________________________________________
________________________________чараларын тормышка ашыруга бер тапкыр түләнелә торган ________сумма күләмендәге түләүне түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк: ______________________________________________________
БИК (банкның таныклаучы коды) алучы банк
____________________________________
Сч. № ________________________________
Сч. № алучы_______________________________________

ИНН ________________________________

КПП ________________________________________

КБК ______________ ОКАТО _________________

Түләүнең билгеләнеше
______________________________________________________________________

Җитәкче _________________ ______________________________
М.У. (имза) (имзаның расшифровкасы)

- - - - - - - - - - - - - - - - - **кисү сызыгы** - - - - - - - - - - - - - - -

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “_____________ авыл (шәһәр) җирлеге” муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнелә торган ________________сум күләмендәге түләүне түләү турында ХӘБӘРНАМӘ №_________
Түләүченең Ф.И.А.и. ____________________________________________________
Адрес:_______________________________________________________________
Алдым “____” ________________, 20__ ел
____________________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта ертып алына торган төпсә тутырыла һәм _______________җирлеге Башкарма комитетында кала.*